Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советының
бишенче чакырылышының икенче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

16 октябрь, 2025 ел № 12

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, 2024 елның 8 августындагы 317-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе Җир кодексының 11.10 һәм 39.15 статьяларына һәм «Геодезия, картография һәм пространство мәгълүматлары турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 18.1 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 7 июнендәге 1040 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бердәм цифрлы мәгълүматлар системасы» федераль дәүләт географик мәгълүмат системасы турында» 1040 номерлы карары, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы уставы нигезендә **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2020 елның 25 ноябрендәге 28 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы турында (2021 елның 27 октябрендәге 111 номерлы, 2013 елның 30 апрелендәге 228 номерлы үзгәрешләрне исәпкә алып), түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 пунктка түбәндәге эчтәлекле 3.45 пунктча өстәргә:

«3.45. Палатның үз вәкаләтләрен тәэмин итү өчен дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системаларын, шулай ук пространстволы мәгълүматларның милли системасы эшчәнлеген тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасын куллану хокукы бар.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Питрәч муниципаль районы башлыгы Р.Ә. Сөләйманов

СОВЕТ ПЕСТРЕЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ИНН 1633605407